## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
## УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### КАРАР

2 номерлы

2020 елның 16.03

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетының
«2016-2020 елларга Урмандеево авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү" муниципаль
максатчан программасын раслау турында"
2015 елның 13 ноябрендәге 22 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль берәмлекнең хокукый базасын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы таләпләренә туры китерү, "Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 27 декабрендәге 104 - ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә, программа-максатчан планлаштыру тәртибен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Уставына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетының «2016-2020 елларга Урмандеево авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль максатчан программасын раслау турында" 2015 елның 13 ноябрендәге 22 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "2016-2020 елларга Урмандеево авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль программасын раслау турында".
1.2. Программа тексты буенча "муниципаль максатчан программа" сүзләрен "муниципаль программа" сүзләренә алмаштырырга, тиешле килештә һәм санда.

2. Программага кушымта итеп бирелә торган редакция нигезендә кушымтаны бәян итеп, чаралар юнәлешләре буенча финанслау күләмнәрен бүлү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Урмандеево авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: В.З.Николаев

Программага кушымта.

«2021- 2025 елларга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү» муниципаль программасының төп чаралары.
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Савруш авыл җирлеге”.

| № т/б | Чаралар | Еллар буенча чаралар үтәлеше | | | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| 1 | Автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын карап тоту, торак пунктларның урамнарын кардан чистарту | 5км 30000 сум. | 5км 30000 сум. | 5км 30000 сум. | 5км 30000 сум. | 5км 30000 сум. | Финанслау күләме. Программа прогнозланган характерда һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга республика һәм район бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |
| 2 | Торак пунктларның урамнарны яктырту | 13км 295000 сум | 13км 295000 сум | 13км 295000 сум | 13км 295000 сум | 13км 295000 сум | |
| 3 | Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту | 6 зират 10000 сум | 6зират 10000 сум | 6 зират 10000 сум | 6 зират 10000 сум | 6 зират 10000 сум | |
| 4 | Чишмәләрне төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 5 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 6 | Обелискларны төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| | Барлыгы | 320000 | 320000 | 320000 | 320000 | 320000 | |